КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 сентябрь г.Казань № 784

2020/2021 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020/2021 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын;

2020/2021 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәрен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019/2020 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын –

эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен раслау турында» 2018 ел, 17 сентябрь, 785 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2020 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 сентябрь, 784 нче
карары белән расланды

2020/2021 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнары

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) исеме | Уку-укыту вакыты, ай | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 5 | 9 407 | 10 595 |
| 43.01.09 | Пешекче, кондитер | 4 | 6 739 | 7 532 |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 5 580 | 6 272 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 5 | 10 264 | 11 633 |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 сентябрь, 784 нче
карары белән расланды

2020/2021 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәре

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) исеме | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә дәүләт хезмәте күрсәтү күләме, кеше |
|---|---|---|
| «Мамадыш политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 40 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 20 |
| 43.01.09 | Пешекче, кондитер | 20 |

______________________________